| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КЕРЛИГАЧСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КИРЛЕГӘЧ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 2 октябре** **№ 20**

**Кирлегәч авыл җирлеге Кирлегәч авылы территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьялары, Кирлегәч авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы карар КАРАР БИРДЕ:

1. 2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Кирлегәч авыл җирлеге Кирлегәч авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. «2019 елда Кирлегәч авыл җирлеге Кирлегәч авылы чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән һәр гражданнан 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан файдалану белән килешәсезме соравы буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә

расланган исемлек нигезендә суүткәргеч мөлкәтен карап тоту; бирелгән вәкаләтләр нигезендә җирлекнең суүткәргеч объектларын ремонтлау объектлары;

авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә юлларны карап тоту;

« Әйе Юк».

3. Әлеге карарны Кирлегәч авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре»

бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Кирлегәч авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы С.Р.Сәлахова